ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы предприятиеләренә заманча икътисадый шартларда ярдәм чаралары турында

Татарстан Республикасы предприятиеләренә заманча икътисадый шартларда ярдәм чаралары турында «Түбән Кама нефтехим» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты М.И. Фәлахов, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры О.В. Коробченко мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы предприятиеләренә заманча икътисадый шартларда ярдәм чаралары турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Химия һәм нефть химиясе тармагы предприятиеләренә, технологик җиһаз сатып алуга ташламалы кредит бирү программаларын һәм кредитлар буенча процент ставкаларын субсидияләүне дә кертеп, финанс ярдәме чараларын киңәйтү мөмкинлеген карарга.

2.2. Яңа техника һәм яңа технологияләр эшләү һәм аларны гамәлгә кертү максатларында Татарстан Республикасы предприятиеләре арасында кооперация бәйләнешләрен үстерү өчен уңай шартлар тудыру буенча республика башкарма хакимият органнары гамәлләрен координацияләүне тәэмин итәргә.

2.3. Предприятиеләрне технологик яңадан җиһазлауга юнәлдерелгән проектларны финанслау өчен Татарстан Республикасы Сәнәгатьне үстерү фонды акчалары күләмен арттыру мөмкинлеген карарга һәм Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга федераль үсеш институтлары акчаларын җәлеп итү эшен көчәйтергә.

3. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән берлектә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләренең технологик модернизацияләүгә һәм импортны алмаштыруга юнәлдерелгән инвестиция проектларына ярдәм итү эшен дәвам итәргә.

3.2. Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләренең иң мөһим компонентларга һәм комплектлау әйберләренә ихтыяҗын республика башкарма хакимиятенең тармак органнары белән мониторинглауны тәэмин итәргә.

3.3. Татарстан Республикасы предприятиеләренә кооперация-платформа инструментлары ярдәмендә продукция сату базарын киңәйтүдә булышлык күрсәтү эшен активлаштырырга.

3.4. Импортны алмаштыру өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы предприятиеләренә дәүләт ярдәме механизмнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләргә.

4. «СИБУР» холдингына керүче «Түбән Кама нефтехим» гавами акционер җәмгыятенә һәм Татарстан Республикасының башка эре сәнәгать предприятиеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Татарстан Республикасының фән-мәгариф оешмалары белән яңа һәм импортны алмаштыручы технологияләрне эшләү һәм гамәлгә кертү мәсьәләләре буенча эшчәнлекне көчәйтергә.

4.2. Платформалы икътисадны булдыру принципларында технологик модернизацияләү һәм импортны алмаштыру программаларын гамәлгә ашыру эшен активлаштырырга.

4.3. Импортны алмаштыру программаларын гамәлгә ашыру кысаларында кече һәм урта предприятиеләр һәм кече технологик компанияләр белән кооперация багланышларын киңәйтергә.

5. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына тиешле муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан Татарстан Республикасы предприятиеләренә кадрлар белән тәэмин итү, республика һәм федераль ярдәм программаларында катнашу мәсьәләләрендә оештыру ягыннан ярдәм һәм консультация ярдәме күрсәтүне тәкъдим итәргә.

6. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

6.1. Татарстан җитештерүчеләренең казанышларына басым ясап, технологик суверенитет һәм импортны алмаштыру чараларын мәгълүмати яктыртуны тәэмин итәргә.

6.2. Массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасы предприятиеләренең заманча икътисадый шартларга яраклашуының нәтиҗәле стратегияләрен күрсәтә торган материалларны урнаштыруга аерым игътибар бирергә.

7. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына республика башкарма хакимиятенең тармак органнары белән берлектә җитешсезлекләрне һәм җитәрлек дәрәҗәдә нәтиҗәле булмаган механизмнарны ачыклау максатында Татарстан Республикасы предприятиеләренә дәүләт ярдәме өлкәсендәге законнарга комплекслы анализ ясарга һәм, кирәк булганда, законнарны камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары М.Г. Әхмәтовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Түбән Кама шәһәре
2025 елның 23 октябре
№ 120-VII ДСП